ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.11.2024 п.г.т.Алексеевское № 529

**Муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатулар уздырмыйча милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Җир кодексының 39.16 статьясындагы 8, 9, 10 пунктларына үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә

**карар бирәм:**

1. Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 29.09.2021 ел, № 358 карары белән расланган Административ регламентына (3 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

- 2.8.2.1 Пунктында 8, 9 һәм 10 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

8) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән йә аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә, моңа җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге җир кишәрлегендә урнашкан бина, корылма, биналар милекчесе яисә мондый җир кишәрлегенең хокукый иясе мөрәҗәгать иткән булса;

9) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә башка зат белән төзелгән йә аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, әгәр әлеге карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә яисә җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә башка зат белән төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән булса, моңа территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә очраклары керми, әгәр мондый җир кишәрлеге федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән булса һәм мондый җир кишәрлеген

биру турында гариза белән күрсәтелгән объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән булса;

10) җир кишәрлеге биру турындагы гаризада күрсәтелгән җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән йә, күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, аны комплекслы үстерү турында Карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документлар нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен яисә җирле әһәмияттәге объектлар, җир кишәрлеген арендага биру турында гариза белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш, әлеге затның күрсәтелгән объектларны төзү буенча йөкләмәсен күздә тота;

2. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Э.Н.Павловага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**